ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

2023 елның 28 августы Новотроицк авылы № 1

Тукай муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлеге бюджеты хисап
проекты үтәлеше буенча
2023 елның 1 яртыеелыгында ачык
тыңлауларын үткәрү турында

Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге халкының «2019 ел өчен Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында ниге зләмәгә таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге бюджетының 2023 елның 1 яртыеелыгында үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълумат стендларында һәм Тукай муниципаль районның рәсми сайтында 2023 елның 31 августыннан да соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Билгеләргә
- уздыру көне - 1 көн;
- үткәрү вакытын - 2023 елның 08 сентябре 15.30 сәгатьтә;
- үткәрү урынын - Тукай районы, Новотроицк авылы, Ленин урамы, 16 йорт (Новотроицк авыл жирлеге башкарма комитеты бинасы);
- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим итү, чыгыш; чыгыш хокукы белән халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү адресын - Тукай районы, Новотроицк авылы, Ленин урамы. 16 йорт (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр);
- чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты - 2023 елның 7 сентябренә кадәр.

4. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге башкарма комитетына «Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге бюджетының 2023 елның 1 яртыеелыгында үтәлеше турында хисап» карары проекты буенча ачык тыңлауларны бирелгән вакытта әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Новотроицк авыл жирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева